ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2019 елның 11 июлендәге 2983-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2022, № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $5^{1}$ пункт өстәргә:
«$5^{1}$. Яшьләр парламенты әгъзасының вәкаләтләре ул 36 яшькә җиткәнче саклана.»;

2) 6 пунктның 2 пунктчасында «сәяси партияләрне» сүзләреннән соң «(алга таба – иҗтимагый оешмалар)» сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $7^{1}$ пункт өстәргә:
«$7^{1}$. Бер үк зат бер үк вакытта Яшьләр парламенты әгъзасы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты оештырган Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте составына керүче була алмый.»;

4) $11^{1}$ һәм $11^{2}$ пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$11^{1}$. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары яшьләре арасыннан булган Яшьләр парламенты әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, тиешле исемлектәге иң күп тавыш җыйган чираттагы кандидат Яшьләр парламенты әгъзасы була.

Исемлектә тавыш җыйган башка кандидатлар булмаган очракта, Яшьләр парламенты әгъзасын сайлау әлеге Нигезләмәгә таянып конкурс үткәрү юлы белән башкарыла.

11$^{2}$. Иҗтимагый оешмалардан булган Яшьләр парламенты әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, күрсәтелгән иҗтимагый оешмалар җиде көн эчендә яңа кандидатура турында Яшьләр парламенты советына тәкъдим кертергә мөмкин, ул 10 көн эчендә аны Яшьләр парламенты составына кабул итү турында карар кабул итә. Күрсәтелгән иҗтимагый оешмалардан җиде көн эчендә яңа кандидатура турында тәкъдим кермәгән очракта, иҗтимагый оешмалардан исемлектәге иң күп тавыш җыйган чираттагы кандидат Яшьләр парламенты әгъзасы була.»;

5) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс турында нигезләмәдә:

а) 12 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурста Яшьләр парламенты әгъзасына кандидатлар сыйфатында кире алынмаган (үтәлеп бетмәгән) суд хөкеме булган, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 – 20.3$^{4}$ һәм 20.29 статьяларында каралган административ хокук бозулар кылган өчен административ җаваплылыкка тартылган (җәлеп ителгән) йә чит ил агентлары реестрына кертелгән затлар катнаша алмый.»;

б) 31 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31. Муниципаль районнардан, шәһәр округларыннан кандидатлар исемлеге буенча Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлегендә иң күп тавыш җыйган кандидатлар конкурста җиңүчеләр дип танала. Тавышлар саны тигез булганда, махсус хәрби операция барышында бурычлар үтәүне тәэмин итүдә катнашкан затлар, шулай ук хәрби хезмәт яисә аңа тиңләштерелгән башка хезмәт узган гражданнар Яшьләр парламенты составына кертелүгә өстенлекле хокукка ия була.».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе　　　Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2596-VI ДС